МИНИСТЕРСТВО СПОРТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.03.2025 Казан шәһәре 77

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2021 елның 28 декабреннән «Спорт әзерлеге программаларына язылу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 562 нче номерлы боерыгы белән расланган Спорт әзерлеге программаларына язылу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының норматив хокукый актын 2010 елның 27 июленнән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы федераль законның 5 маддәсенә туры китерү максатларында

**б о е р а м:**

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2021 елның 28 декабреннән «Спорт әзерлеге программаларына язылу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 562 нче номерлы боерыгы белән расланган Спорт әзерлеге программаларына язылу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2022 елның 1 августыннан 346 нчы номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәреш белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.6.5 нче пункт. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.5. Гариза бирүчеләр гаризада түбәндәге мәҗбүри белешмәләрне күрсәтәләр:

1) фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

2) туу датасы һәм урыны;

3) теркәлү адресы, чынбарлыкта яшәү урыны адресы;

4) гариза бирүченең шәхесен раслаучы документның реквизитлары;

5) телефон, электрон почта адресы (булган очракта);

6) спорт төре, спорт әзерлеге программалары;

7) тәрбияләнүче өчен керү сынауларын үткәргәндә аның инвалидлыгы яисә сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнүе сәбәпле махсус шартлар тудыру зарурлыгы;

8) дәүләт хезмәтен күрсәтүнең кәгазьдәге документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәсен, шәхсән яисә гариза бирүче булып тормаган балигъ

булмаган баланың башка законлы вәкиле тарафыннан алу турында мәгълүмат.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен гариза бирүче булып тормаган балигъ булмаган баланың законлы вәкиле алу кирәк булган очракта, гаризада гариза бирүче тарафыннан балигъ булмаган баланың кәгазьдә документ формасында рәсмиләштерелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алуга вәкаләтле башка законлы вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), шәхесен раслаучы документ турында белешмәләр күрсәтелә.

Гариза бирүченең имзасы белән шулай ук түбәндәгеләр раслана:

тәрбияләнүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы;

учреждение уставы, спорт әзерлеге программалары һәм тренировка эшчәнлеген оештыруны һәм гамәлгә ашыруны, тәрбияләнүчеләрнең хокукларын һәм бурычларын җайга салучы башка документлар белән танышу.»;

2.6.7. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.7. Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында вәкаләтле органнардан белешмәләр алына:

1) СНИЛС номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды;

2) инвалидлык турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды;

3) опека билгеләүне раслый торган документ – Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы.»;

3.3.2.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә::

«Гаризаны формалаштыру башка нинди дә булса формада өстәмә гариза бирү зарурлыгыннан тыш ДХБП да, «Минем спорт» АМС Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән башкарыла.

Төзелгән гаризаны формат-логик тикшерүне орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, гариза бирүче гаризаның электрон формасындагы һәр кырын тутырганда, Бердәм портал автомат рәвештә гамәлгә ашыра. Бердәм портал, гаризаның электрон формасында дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында гаризаның электрон формасында мәгълүмати хәбәр аша турыдан-туры белдерә.

Гариза формалаштырганда гариза бирүчегә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документларны күчереп алу һәм саклап калу мөмкинлеге;

б) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастыру мөмкинлеге;

в) гаризаның электрон формасына элек кертелгән күрсәткечләрне кулланучы теләге буенча теләсә кайсы вакытта, шул исәптән гаризаның электрон формасына кыйммәтләрне кертүдә хаталар килеп чыкканда һәм кабат кертү өчен кире кайтарганда саклау;

г) гариза бирүче белешмәләрне кертә башлаганчы, ИАБСда урнаштырылган белешмәләрдән һәм ДХБП да, Республика порталында бастырылган белешмәләрдән файдаланып, ИАБС да булмаган белешмәләргә кагылышлы өлештә гаризаның электрон формасындагы кырларны тутыру;

д) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, гаризаның электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этабына кире кайту мөмкинлеге;

е) гариза бирүченең ДХБП да, Республика порталында элек бирелгән гаризалардан кимендә бер ел дәвамында, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризалардан кимендә 3 ай дәвамында файдалана алу мөмкинлеге.

Төзелгән һәм имзаланган гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар учреждениегә ДХБП, Республика порталы аша җибәрелә.»;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара сораулар (запрослар) җибәрү.

3.4.1. Административ процедураны башкара башлау өчен нигез булып административ процедураны башкаруга вәкаләтле вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи заттан (хезмәткәрдән) гариза бирүчедән кабул ителгән документларны алуы тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып учреждение хезмәткәре (алга таба – ведомствоара сорауларны җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат) тора.

3.4.2. Ведомствоара сораулар җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат әлеге Административ регламентның 2.6.7 пунктында каралган документлар һәм белешмәләр бирү турындагы сорауларны ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә (техник мөмкинлекләре булмаганда – башка ысуллар белән) электрон формада төзи һәм җибәрә.

3.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган сорала торган документлар исемлеге:

1) СНИЛС номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды;

2) инвалидлык турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды;

3) опека билгеләүне раслый торган документ – Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы.

Ведомствоара мәгълүмат сорау гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында күрсәтелгән органнарга ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәү көнендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып хакимият органнарына һәм (яисә) хакимият органнары буйсынуындагы оешмалар җибәрелгән сораулар тора.

3.4.4. Әлеге Административ регламентның 2.6.7 сендә каралган белешмәләр ведомствоара соратулар буенча әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан 2021 елның 23 июненнән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм (яки) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек

оештыруның тәкъдим ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 963 нче номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә тиешле ведомствоара сорау җибәрелгән вакыттан алып 48 сәгатьтән дә соңга калмыйча бирелә.

3.4.5. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазьдә гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1 сорала торган белешмәләр электрон рәвештә булмау сәбәпле, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон рәвештә гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда;

2) ведомствоара сорау юллаганда документларның төп нөсхәләрен кәгазьдә тапшыру кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазьдә гамәлгә ашырылса, әлеге Административ регламентның 2.6.7 пунктчасында каралган белешмәләр күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан тапшырыла.

Ведомствоара сорауларга җавап әзерләү һәм җибәрү вакыты 210-ФЗ номерлы Федераль законның $7^2$ маддәсендәге 3 нче өлеше нигезендә ведомствоара сорау кергән көннән алып биш эш көненнән артмаска тиеш.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән сораулар, сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яисә аларда булган белешмәләрне) алу.

Белешмәләрдән файдалануның максатлары булып гариза бирүче тапшырган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук гариза бирүченең законнарын һәм хокукларын бозуны булдырмаслык карарлар кабул итү тора.»;

3.6.2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2.1. Гариза бирүче, дәүләт хезмәте нәтиҗәсен сорап учреждениегә мөрәҗәгать иткәндә, учреждение хезмәткәре гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен кәгазьдә бирә. Гариза бирүченең таләбе буенча аңа электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе белән бергә электрон документ нөсхәсе мәгълүмат йөртүче алына торган җайланмага яздырып бирелергә яки гариза бирүче адресына электрон почта буенча җибәрелергә мөмкин.

Гаризада гариза бирүче булмаган балигъ булмаган затның законлы вәкиленең балигъ булмаган затка карата дәүләт хезмәте күрсәтүнең кәгазьдә тутырылган документ формасындагы нәтиҗәсен алу турында белешмә күрсәтелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе, аның шәхесен раслаучы документ күрсәтелгәндә, әлеге затка бирелә.

Әгәр гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризада дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен шәхсән үзе алу турында күрсәткән булса, балигъ булмаган затка карата дәүләт хезмәтен күрсәтүнең кәгазьдә язылган документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәсе балигъ булмаганның башка законлы вәкиленә бирелми.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче килгән көнне учреждениенең эш регламентында билгеләнгән вакытларда чират тәртибендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (законлы вәкилгә) дәүләт

хезмәте күрсәтү турындагы боерыктан өземтәне яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы белешмәне юллау (бирү).»;

Спорт әзерлеге программаларына язылу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Х.Х. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Министр вазыйфаларын башкаручы Х.Х.Шәйхетдинов

Спорт әзерлеге программаларына
язылу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

*Тәкъдим ителә торган форма*

Теркәү номеры ______________

Татарстан Республикасы
Спорта министлыгына

дан ______________________________
(Ф.И.А.и. (булганда))

______________________________
Туу датасы һәм урыны: _________________

______________________________
Теркәлү адресы: _____________________

______________________________
Чынбарлыкта яшәү урыны адресы:

______________________________

______________________________
Шәхесне раслаучы документ:

______________________________
(серия, №, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

______________________________

______________________________
Телефон: ___________________________
Электрон почта адресы _______________
(булганда)

ГАРИЗА

Мине ______________________________________________
(фамилия, имя, атасының исеме (булганда)

Спорт әзерлеге программасын:

______________________________________________________________.
(программа атамасы)

үтүгә язуыгызны сорыйм.
Җайлаштырылган программа буенча спорт әзерлеген оештыруга, инвалид балаларны инвалидны реабилитацияләүнең индивидуаль программасы нигезендә спорт әзерлеген оештыру өчен махсус шартлар тудыруга ихтыяҗ (булган очракта)

______________________________________________________________
(нигез)

Миңа дәүләт хезмәте нәтиҗәләре турында хәбәр итүегезне

сорыйм_________________.
(хәбәр итү ысулын күрсәтергә)

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен кәгазьдә бирергә:

- шәхсән миңа
- мөрәҗәгать итүче булмаган башка законлы вәкилгә

_______________________________________________________________________
(Ф.И.А.и, шәхесне раслаучы документ турында белешмәләр)

Документлар тапшырганда түбәндәгеләр белән таныштым:

- учреждение Уставы _____________________
(гариза бирүче имзасы)

- эчке тәртип кагыйдәләре ___________________
(гариза бирүче имзасы)

Үземнең шәхси мәгълүматларымны, балигъ булмаганнарның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык бирәм ______________________
(гариза бирүче имзасы)

Дата «___» _____________ 20___ ел

___________________
(гариза бирүче имзасы)